ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, 5, с.Бишня,
Зеленодольский район, 422528

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИШНӘ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Центральная ур., 5, Бишнэ ав,
Зеленодольск районы., 422528

**Тел/факс: (84371) 6-46-10. E-mail: Bsn.Zel@tatar.ru**

# КАРАР

2016 елның 28 ноябре №39

Бишнә авыл җирлегенең азкатлы шәхси торак төзелеше территориясеннән 2017 елга каты көнкүреш калдыкларын чыгару турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты көнкүреш калдыкларын чыгару буенча хезмәтләр күрсәтү Кагыйдәләрен раслау турында»гы 1997 елның 10 февралендәге 155 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында»гы 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы карары нигезендә һәм чисталыкны тәэмин итү, йогышлар таралуны булдырмау һәм экологик хәлне яхшырту максатларында,карар итәм:

1. Тәкъдим итәргә:

1.1. Бишнә авыл җирлеге территориясеннән чүп чыгару буенча хезмәт күрсәтүче шәхси эшмәкәрләргә, аларның оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә, югарыда күрсәтелгән территориядә яшәүче кулланучылар белән килешүләр төзергә.

1.2. Килешү төзегәндә каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару һәм утильләштерү хезмәтләре күрсәтү бәясе бер кешегә аена 51,48 сумнан да артмаска.

1.3. Теркәлгән гражданнар булмаган очракта, Бишнә авыл җирлегендәге азкатлы торак йортлардан каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару һәм утильләштерү хезмәте күрсәтү бәясе йорт хуҗалыгыннан аена 51,50 сумнан да артмаска.

2. Признать утратившим силу постановление руководителя исполнительного комитета Бишнинского сельского поселения «О вывозе твердых бытовых отходов с территории малоэтажной индивидуальной

жилищной застройки Бишнинского сельского поселения» № 78 от 24.11.2015г.

Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Бишнә авыл җирлегенең азкатлы шәхси торак төзелеше территориясеннән каты көнкүреш калдыкларын чыгару турында"гы 2015 елның 24 ноябрендагы 78 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

**Бишнә авыл жирлеге башлыгы** **И.М.Фатхуллин**